СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

20.11.2023 с. Сарманово № 195

Сарман муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында» 2019 елның 07 октябрендәге 194 номерлы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 19 декабрендәге 521-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2022 N 562-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 4 пунктындагы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 28.12.2022 номерлы Федераль закон, Сарман районы Прокуратурасының 02.03-01-21/2023 номерлы мәгълүматы, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Сарман муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турында Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының 2019 елның 07 октябрендәге 194 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 13 статьяның 2 пунктындагы 2 абзацына түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче һәм бишенче абзацлар өстәргә:

«җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыр йөкле транспорт чаралары китерә торган зыянны каплау исәбенә җирле бюджетларның керемнәре;

авыр йөкле һәм (яисә) эре габаритлы транспорт чарасының хәрәкәт итү кагыйдәләрен бозган өчен җирле бюджетлар керемнәре;

Алдагы редакциянең дүртенче - алтынчы абзацлары тиешенчә алтынчы - сигезенче абзацлар дип санала».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Сарман муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://sarmanovo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы

Совет рәисе Ф.М. Хөснуллин